ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында” 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 6; 2012, № 1, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяда:
а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5. Конкурс үткәрү турында хәбәр, шулай ук конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат заказчының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына конкурс үткәреләчәк көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.”;
б) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“11. Конкурска кертү тәртибе, конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе һәм шартлары, шулай ук конкурс документлары Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге вәкаләтле органы һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә раслана.”;

2) 14 статьяның 2 өлешендәге җиденче абзацында “әлеге Законның 15 статьясындагы 3 өлеше нигезендә техник хезмәт күрсәтү эшләрен теркәргә” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 15 статьяда:
а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Транспорт чараларының юл хәрәкәте иминлегенең мәҗбүри таләпләренә туры килүе транспорт чараларын техник тикшерү өлкәсендәге законнарда каралган транспорт чараларын техник тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән документ белән раслана.";

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Транспорт чараларының техник халәт һәм җиһазлану таләпләренә туры килүен, транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтүне үткәрү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешен, транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтелүне һәм ремонт ясалуны һәм аларны техник тикшерүне раслаучы документларның булуын тикшереп торуны тиешле дәүләт органнары һәм пассажир йөртүчеләр гамәлгә ашыра.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 15 декабре
№ 116-ТРЗ